# Ислам нуры

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәту бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№ 12 (664) 25 июнь 2018 ел (1439, Шәүвәл) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга


## Бәйрәм мөбарәк булды



Чаллыда Ураза гаете бик матур бәйрәм чарасы рәвешендә узды. Мәчет заллары иртәнге алтыда ук халык белән тулды, бәйрәм вәгазьләре дә алдан башланды. Гает намазына килүчеләр күп булу сәбәпле, аларны намаз заллары сыйдыра алмады. Кайбер дин кардәшләребез гает намазын мәчет ишек алдында укыды. Гает намазы тәмамлану белән "Җәмигъ", "Рамазан", "Ихлас", "Туфан", "Кәүсәр", "Чишмә", "ГЭС", "Нур-Ихлас", "Әбүзәр" мәчетләрендә килгән халыкны пылау, чәй, гает коймагы белән сыйладылар. "Туфан" мәчете мохтаҗларга 50 хәйрия пакеты таратты. Ә "Әбүзәр" мәчете азык-төлек салынган пакетларны мәчет картларына, абыстайларына, мәхәлләдә яшәүче мохтаҗларга 12 июньдә үк тапшырган иде. Моннан тыш бу мәчет "Снежок" ял базасында күп балалы гаиләләр һәм ятимнәр өчен ял чаралары уздырды. Мәчет имам-хатыйбы Али хәзрәт Баһаветдин башлангычы белән тормышка кергән бу хәйрия чарасы ел саен үткәрелеп килә һәм анда 150-200 кеше катнаша. "Утыз Имәни" мәчете, "Ихлас" мәчете белән берлектә, "Бумажник" ял базасында мөселман гаиләләре өчен ял оештырды.

"Сөембикә" мәчете һәм "Хәләл-Үзәк"кә килгән халык та тәмле пылау белән сыйланды, балалар исә төрле кызыклы уеннарда күңел ачтылар. Алар өчен иң зур аттракцион шәһәрнең "Нур-Ихлас" мәчетендә узды. Биредә балалар төрле бәйгеләрдә, викториналарда катнашып, савап карточкалары алдылар һәм аларны бәйрәм сәүдәсендә кулланып бүләкләргә ия булдылар.

Шәһәр имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин гает намазын "Нур-Ихлас" мәчетендә укытты. Биредә шәһәр мэры Наил Гамбәр улы Мәһдиев, шәһәр эчке эшләр идарәсе башлыгы Надир Дамир улы Закиров, шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Рамил Мәрван улы Хәлимов, Татарстан Дәүләт советы депутаты Рафаэль Сәләйман улы Юнысов, башка рәсми кешеләр дә катнашты. Соңыннан алар гает хөрмәтенә оештырылган чәй мәҗлесендә бәйрәм сыеннан авыз иттеләр. Наил Гамбәр улы бәйрәм барышында мөселманнар белән аралашты һәм очрашу вакытында дин кардәшләребезне олуг бәйрәмебез белән котлады.

## Сабантуйлар дәвам итә



2018 елның 15 июлендә Балтач районының Бөрбаш авылында Республикакүләм мөселман балалар сабан туе уздырылачак. Бик күп кунаклар, хөкүмәт вәкилләре, дин әһелләре, күренекле шәхесләр катнашында уздырыла торган әлеге күркәм чара Балтач районы имам-мөхтәсибе, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыевның тырышлыгы белән унберенче тапкыр оештырыла. Сабантуйда шулай ук чит төбәкләрдән дә мөселман дини оешма вәкилләре: Ульян, Самара, Киров өлкәсе, Мари Эль, Чувашия республикалары мөселманнарының да кунак булуы көтелә. Сабантуй балаларның Коръән һәм догалар укулары, мөнәҗәт әйтүләр, шигырьләр белән үрелеп барачак.

Бәйрәм кысаларында балалар өчен төрле уеннар, ярышлар, рухи кыйммәтләрне барлаучы чаралар оештыру каралган. Моңардан тыш, 35, 50, 65 килограммга кадәрге һәм аннан югарырак үлчәү категорияләрендә балалар арасында көрәш бәйгесе булачак. Җиңүчеләргә кыйммәтле бүләкләр биреләчәк.

## Ерактагы якын кардәшләр



ТР мөселманнары Диния нәзарәтенә Татарстан мөфтие белән очрашуга Австралиянең татар-башкорт җәмгыяте рәисе Шәһрәт Вәли килде. "Милләттәшләребез белән аралашып торабыз. Аделаида шәһәрендә татар мәчете эшли, вәгазьләребез бары татар телендә алып барыла, балаларыбызга татар телен, дин нигезләрен өйрәтәбез", – дип белдерде Австралия татарлары җитәкчесе. Камил хәзрәт үз чиратында кунакны Диния нәзарәтенең туган телебезне саклауга һәм үстерүгә багышланган проектлары белән таныштырды, "Хозур ТВ" каналы эшчәнлеге турында сөйләде, очрашу ахырында татар телендә дини әдәбият бүләк итте.

## Яшьләр форумы узачак

Казанның Горький исемендәге Үзәк мәдәният һәм ял итү паркында Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең мөселман яшьләр хәрәкәте активистлары очрашуы узды. Алар VI Мөселман яшьләре форумын оештыруда катнашачаклар. VI Мөселман яшьләре форумы 22-29 июль көннәрендә Болгар шәһәрендә узачак һәм ике йөздән артык катнашучыны җыячак.

## Киңәшле эш таркалмас

Диния нәзарәтендә Апас һәм Лениногорск районнары мөхтәсибләре белән эшлекле очрашулар уздырылды, аны Мансур хәзрәт Җәләлетдинов алып барды. "Көн саен Апас районы буенча дүрт меңнән артык кеше ифтар мәҗлесләрендә катнашты, 55 мәчеттә тәравих намазлары укылды. Төркиядән килгән Коръән-хафиз белән районның егермедән артык мәчетендә булдык", – диде Мирхәт хәзрәт Җамалиев, үткән Рамазан аена нәтиҗәләр ясап.

Лениногорск мөхтәсибе Исмәгыйль хәзрәт Сингатуллин да райондагы дини вәзгыять белән таныштырды. Мөфти урынбасары Диния нәзарәтенең чираттагы Пленумын Лениногорск шәһәрендә үткәрү теләге барлыгын җиткерде һәм шушы чарага әзерлек буенча эш башларга килештеләр.

# Гомәр разыяллаһу ганһүнең көлүе һәм елавы

Бервакыт пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең иң якын сәхәбәләреннән булган Гомәр ибн Хаттаб көлә һәм елый, көлә һәм елый икән. Гаҗәпләнеп сорыйлар: "Ни өчен син көләсең һәм елыйсың?" Ул әйтә: "Көләм, чөнки элек без, әле пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә динне алып килгәнче, потларга табына һәм сәфәргә чыкканда үзебез белән пот ала идек. Бервакыт сәфәргә чыктык һәм пот алырга онытканбыз. Үзебез белән бары тик хөрмәләр бар иде. Шул хөрмәләрдән пот ясадык та шуңа табындык. Сәфәребез озын булып, ашарыбызга берни калмагач, бары шул пот кына калгач, аны сүтеп ашадык", – ди. "Ә ни өчен елыйсың?" – дигәч, әйтә: "Көннәрдән беркөнне кыз балам туды. Мин ул хурлыкка биш ел түздем. Биш ел узганнан соң кызымны тереләй күмәр өчен алып киттем. Кулыма кәтмән алып җирне казый башладым. Җирне казыган вакытта йөземә тузан-ком тиядер иде. Шулвакыт кызым: "Әтием, әтием, йөзеңә тузан тигән", – дип аны сөртеп торды. Казып бетердем чокырны. Һәм кызымны этә башладым. Кызым: "Әтием, син нишлисең?" – дип кычкыра. Этеп төшердем. Шуннан соң аның өстенә туфрак ата башладым. Кызым: "Әтием, әтием", – дип кычкырып торды. Аттым туфракны, шушы нәни куллары суынганчыга кадәр. Шуңа күрә елыйм", – ди.

Шушы хәбәрне тыңлаганнан соң пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм елап җибәрә һәм әйтә: "Тагын бер мәртәбә сөйлә әле". Гомәр ибн Хаттаб тагын бер кат сөйли. Ә пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм тагын да катырак елый. "Тагын бер кат сөйлә", – ди. Гомәр ибн Хаттаб тагын сөйли. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм алдагысынан да катырак елый. Һәм янда торган сәхәбәләр әйтәләр: "Нишлисең син, тукта, пәйгамбәребезне елатасың бит". Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә: "Туктатмагыз, сөйләсен, күрегез, мин сезне нинди хәлдән алып чыктым", – ди.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең килүе безне кемнеңдер нәфесенә ияреп кенә чыккан кануннардан азат итеп, Раббыбызның кануннары буенча яшәргә һәм бәхетле тормыш кичерергә мөмкинчелек бирде. Шуңа да пәйгамбәребез галәмнәргә рәхмәт итеп җибәрелгән кеше. Аның килүе кыз балаларны тереләй күмүдән, балаларга хөрмәтсезлектән азат итте, гаиләләр булуына, күп балалар үстерелүгә сәбәп булды. Аллаһы Тәгалә һәрберебезгә аны калебләребездә сөекле пәйгамбәребез дип кабул итеп, аның сөннәте буенча яшәргә насыйп әйләсә иде.

Без төрлечә авырлыклар кичерәбез. Кемнеңдер тәне авырта, кемнеңдер күңеле тыныч түгел. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кичергән авырлыклар тән белән дә, күңел белән дә булган. Үзе туганчы ук атасы үлә. 6 яшенә җиткәч әнисе вафат була. 8 яшендә – бабасы. Ул әтисенең бертуган абыйсы Әбү Талиб белән кала. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өйләнгәч, балалары – уллары бер-бер артлы үләләр. Җиткән кызлары да үзе исән чагында дөньядан китә, бер генә кызы кала. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм алты баласын җирли. Үзенең яраткан, сөекле, бөтен авырлыклар вакытында янында булган хатыны Хәдичә разыяллаһу ганһәне күмә. Ул гына да түгел, иң якын кешеләренең дөньядан китүен күрә. 40 яшендә пәйгамбәрлек килгәч, халыкның үзләре үк турыдан-туры утка, җәһәннәмгә баруын күреп, Аллаһы Тәгаләнең әмере белән аларны гаделлеккә, изгелеккә, Исламга, иманга, бер-береңнең хакын үтәргә чакыра. Һәм шул ук халык, күзләренең томаланган икәнлеген аңламыйча, аның бу эшен бозыклык дип уйлап, аны рәнҗетәләр, өстенә ташлар атып шәһәреннән куалар. Кая чыга? – Чүлгә. Мәдинә шәһәре 450 чакрым ераклыкта. Әле анда көтәләрме, юкмы? Шулвакыт пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өчен иң авыр вакыт була. Бернинди яклаучы табылмыйча, Мәккә халкы аны үтерергә йөргән вакытта, аның янына фәрештәләр килә һәм әйтәләр: "Телисеңме, ике тау арасына кысып бу шәһәрне юк итәбез?" Аллаһы илчесе әйтә: "Юк!"

Әгәр берәр кешедән, ул күршебез булсын, хәтта безгә туганлык җепләре булмаган кеше булсын, берәр авыр сүз ишетсәк яисә аның тарафыннан зарар күрсәк, бу кешегә карата калебебездә ачу булыр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне гаделлеге, хаклыгы, изгелеге өчен аны моңа кадәр игелекле, тугры дип әйткән халык шәһәрдән куа. Һәм ул шушы авырлыкларны узып Мәдинә шәһәренә җитә, акрын-акрын халыкны дингә чакыра.

Шушы хәлләрне кичереп тә пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең 63 яшендә башында һәм сакалында фәкать 17 ак чәче була. Әбүбәкер разыяллаһу ганһү: "Йә Рәсүлуллаһ, чәчең агара башлады", – дигәч, Аллаһы Рәсүле әйтте: "Чәчем агара "Һуд" сүрәсе өчен". Чөнки "Һуд" сүрәсендә кыямәт көненең дәһшәтле вакыйгалары аңлатыла. Ягъни ни өчен агара булып чыга? Безне кайгыртып. Бит пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең үткән һәм киләчәк гөнаһлары кичерелгән, аның җәннәткә керәсе билгеле иде. Үзе өчен түгел, өммәте өчен – әгәр дә өммәте, диннән ерагайса, нинди куркыныч хәлгә төшәсен аңлап кайгыра. Без аңламаган нәрсәне аңлап, өммәтем, өммәтем, дип елый-елый дога кыла.

Аллаһы Тәгалә пәйгамбәребезгә карата калебебездә нур балкып торган мәхәббәт уятып, аның сөннәте буенча яшәүгә ашкынып, киләчәктә аның белән күрешкән вакытта безләрне күреп, пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең, өммәтем, дип безләрне сөенеп каршы алуын насыйп әйләсә иде.

**Илназ хәзрәт Яхин,**
**Чаллының "Ихлас" мәчете**
**имам-хатыйбы.**

# Вакыт кадере

Мәшһүр шагыйрь Габделҗаббар Кандалый болай дигән: "Якутлар табыладыр вакыт берлән, Вакытлар табылмыйдыр якут белән". Якут ул – таш, ләкин гади генә таш түгел, ә кыйммәтле асылташларның гомуми аңлатмасы, ягъни, якут дип энҗе, алмаз, зөбәрҗәт кебек ташларга әйтәләр. Асылташны табу өчен тырышлык, көч, гыйлем, вакыт кирәк. Чөнки башта аны тау-таш арасыннан эзләп табарга, аннан, асылташ дәрәҗәсенә җиткерү өчен, эшкәртергә кирәк. Бик күп вакыт сарыф ителгәнлектән, якут – кыйммәтле. Кыйммәт, дәрәҗәле таш биреп тә үткән вакытны кире кайтарып булмый, шуңа күрә һәр минутның, һәр мизгелнең кадерен белергә кирәк.

"Вакыт" дигәндә сәгать, минут, секунд, көн, төн, иртә, кич, атна, ай, ел, гасырларын күздә тотабыз, бу сүз үз эченә бик күп мәгънә сыйдырган. Вакытны файдалы итеп уздырып була: әйтик, китап уку, спорт белән шөгыльләнү, туганнар белән күрешү... Аллаһы Тәгаләгә күбрәк гыйбадәт кылу, гыйлем алу, әти-әнигә булышу, дусларга, мохтаҗларга ярдәм итү... Вакытны кирәкмәгән шөгыльләргә, мәсәлән, бертуктаусыз телевизор карап, компьютерда, телефонда уйнап, кирәкмәгән сүзләр сөйләп утыруга әрәм итмәскә кирәк.

Аллаһы Тәгалә Изге Коръәндә "Гаср" сүрәсендә әйтә:

1. Гасыр белән ант итәм.
2. Дөреслектә адәм баласы хәсрәттәдер, кадерле гомерен дөнья өчен генә әрәм итеп.
3. Мәгәр Коръән өйрәткәнчә дөрес юл белән чын иман китереп Ислам динен кабул иткән мөэминнәр генә хәсрәттә булмаслар.

Имам Шәфигый: "Кешеләр бу сүрәнең тирән мәгънәсенә төшенсәләр, аларга шул да җитәр иде", – дигән. Бу сүрәне сәхабәләр бер-берсенең исләренә һәрдаим төшерә торган булганнар. Безнең дә һәрберебез "Гаср" сүрәсен уку белән үзенең тормышына, эшләгән эшләренә бәя бирә ала.

«Фәҗер» сүрәсендә Аллаһы Тәгалә атып килә торган таң исеме белән ант итә. "Духа" сүрәсендә – иртәнге шәфәкъ белән, ә "Ләйл" сүрәсендә караңгылыгы белән тирә-якны каплаган төн белән ант итә. Бу – вакытның кадерле нигъмәт булуын бик ачык дәлилли. Чөнки Кыямәт көнендә вакытыбызны нинди эшләргә сарыф итүебез өчен җавап бирергә туры киләчәк.

Исламда һәр нәрсәнең вакыты бар: 5 вакыт намаз да төгәл вакытларда укыла, ураза да билгеле вакытта тотыла, хаҗ белән зәкәтнең дә вакыты билгеләнгән. Шулай булгач, без башка эш-гамәлләребезне дә билгеле бер тәртиптә һәм вакытта эшләргә, аларны азагына хәтле җиткерергә тиеш. Иң кирәкле эшләрне төгәл үтәү өчен, вакытыбызны юкка исраф итмәс өчен, безгә көндәлек режимны булдырсак яхшы. Аңа намаз уку, Коръән уку кебек иң мөһим эшләребез керә, болар – фарыз гамәлләребез. Иң беренче итеп намаз вакытларын карыйбыз да, калган эшләребезне намаз вакытларына яраклаштырабыз, шул чакта вакытыбыз бәрәкәтле булыр. Рухи сәламәтлеккә гыйбадәтләр кылып ирешсәк, тән сәламәтлегенә вакытында ашап, тиешенчә йоклап, эш режимын саклап ирешәчәкбез. Вакытны төгәл итеп бүлгән очракта, без бик күп гыйбадәт кылырга, белемебезне арттырырга, төрле эшләр башкарырга өлгерәчәкбез.

Көннең иң бәрәкәтле вакыты – иртәнге намаздан сон булган вакыт. Әгәр дә сез иртәрәк йокларга ятып, иртәнге намаздан соң гыйлем алсагыз, яисә башка файдалы эшләр эшләсәгез, нәтиҗәсен үзегез дә күрерсез, ин шәә Аллаһ. Бу турыда Коръәндә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә: "Мин сезгә яраттым көнне – яшәр өчен, ә төнне яраттым – ял итәр өчен". Игътибар иткәнегез бардыр, көннәр бик тиз уза дә китә. Без кайчакта "вакыт җитмәде, көн җитмәде" дип әйтергә дә яратабыз әле. Көннәр генә дә түгел, атналар, айлар, еллар бер мизгелдә узып киткән кебек була. Вакытның шулай тизләнеше – Ахырзаманның бер билгесе булып тора. Кайбер галимнәр фикеренчә, 1985–86 нчы еллардан вакыт тизлеге арта башлаган, хәзер тәүлектә элеккечә 24 сәгать түгел, ә реаль 18–19 гына. Без моны үзебез дә тоябыз. Бу хакта Пәйгамбәребез (с.г.в.)нең әйткән сүзләре дә бар: "Вакыт тизләшмичә Кыямәт көне җитмәячәк". Шуңа күрә вакытыбызны, көннәребезне ничек үткәрүгә бигрәк тә игътибарлы булырга кирәк. Әгәр буш гамәлләргә вакытыбызны сарыф итсәк, иң мөһим эшләребез үтәлми калуы бар, һәм Кыямәт көнендә моның өчен җавап тотасыбыз булачак.

Танылган галим Ибн Җәүзиягә бер кеше килеп: "Мин бер уен өйрәтәм сиңа, әйдә шуны уйныйбыз", – дигәч, галим: "Вакытны туктатып тор алайса", – дигән.

Башка галимнәрнең дә, яшь булуларына карамасатан, зур дәрәҗәләргә ирешкәннәрен күрәбез. Мәсәлән, дөньякүләм танылган галим Әбүгалисина 10 яшендә Коръәнне тулысынча яттан белгән, 20 яшендә инде медицинаны өйрәнеп, кешеләрне дәвалый башлаган. Имам Нававины карыйк, ул 40 яшенә кадәр яшәгән, 500 китап язып калдырган. Яки Габдулла Тукайны гына алыйк, 27 яшендә вафат булуга карамастан, ул 5 томлык 400 шигырь, 350 әсәр язган. Димәк, бу шәхесләр вакытның кадерен белгәннәр һәм аны дөрес кулланганнар. Без кечкенә чактан ук вакытыбызны дөрес кулланырга өйрәнеп үсәргә тиешбез. Чөнки Кыямәт көнендә яшьлегебезне ничек үткәрүебез хакында аерым соралачакбыз!

Пәйгамбәребезнең сөннәтендә вакытка кагылышлы хәдисләр дә бик күп. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) үзенең бер хәдисендә: "Биш нәрсә килгәнче, башка бишнең кадерен бел: үлемең килгәнче – терек булуыңның, хасталык килгәнче – сәламәтлегеңнең, мәшгуль булганчы – буш вакытыңның, картлык килгәнче – яшьлегеңнең, фәкыйрьлек килгәнче – байлыгыңның", дигән. Хәдистә кеше өчен иң кыйммәтле әйбернең берсе – вакыт икәнлеге турында әйтелә.

Аллаһ Тәгалә барчабызга да вакытыбызның кадерен һәм бәрәкәтен белеп, көннәребезне һәм елларыбызны файдалы гамәлләр кылып яшәргә насыйп итсә иде. Амин.

**Язманы "Хәзинә" клубы мөгаллимәсе**
**Айгөл Шияпова әзерләде.**

# Гадәтләр

Бер егет урман буйлап бара икән. Аның каршына бик затлы киенгән өч адәм килә. Алар юлда очраган һәрнәрсәне җимереп, рәнҗетеп, мыскыллап, талап китәләр икән.

Егет, болардан куркып: “Сез кемнәр?” – диеп сорау биргән.

Ә тегеләр, көлешә-көлешә: “Без синең гадәтләрең”, – дигәннәр.

Егет, тагын да курка төшеп: “Ничек инде минем гадәтләрем?” – дигән.

Адәмнәр, күп сөйләшеп тормый, егетне тирән чокырга төртеп төшерәләр.

Егет бу чокырдан чыгу юлын эзләгәндә, сумкасында бау ятканы исенә төшә. Ул әкрен генә сумкасының кесәләрен капшый башлый. Баудан җилләр искән. Өскә күтәрелеп караса, теге кешеләрнең берсе агач башына бау атып уйный икән. Атып җибәрә дә, озын кулларын сузып, агач башына эләгеп калган бауны ала икән. Ә икенчесе, зур казан асып, аның астына учак ягып, нәрсәдер әзерләмәкче була, ди. Егет куркуга кала. Һәм ул чокыр кырыенда сакта торган өченче адәмгә ялына башлый. “Зинһар, булыш, җибәр инде”, – ди. Ә тегесе, борынын күккә кадәр чөеп, читкә карый.

Егет, котылу өметен өзеп, башын аска ия. Караса, анда нәни генә кырмыска баласы яшәү өчен көрәшә икән. Егет кырмысканы бик кызгана: “И бәләкәч, син булса да яшә, син булса да чык бу чокырдан!” – дип, аны иреккә чыгарып җибәрә. Үзе тагын ялгызы гына кала. Озак уйланып утырганнан соң, Аллаһка соравын бирә:

– Әй Раббым, – ди, – минем бу җирдә бер генә булса да яхшылык эшләгәнем булмады мыни? – ди. Ә өстән әкрен генә кемдер бау төшерә. Караса, бу – иреккә чыгарып җибәргән нәни кырмыска баласы икән... Егет, гаҗәпләнеп: “Кем син?” – дип сораган. Ә кырмыска баласы:

– Мин синең үз гомереңдә кылган беренче яхшылыгың, – дигән.

**Алмаз Әхмәтгалиев, Балтач.**

ӘДӘБИ СҮЗ

*Роберт Сәлахиев,*
*Актаныш, Тат. Суыксу авылы.*

## Онытмыйк!

Аллаһыбыз бер генә дә,
Коръәнебез бер генә.
Безгә биргән гомерләрнең
Кадерләрен бел генә.
Сынар өчен Хак Тәгалә
Төрле хәлләргә дәшә.
Иманыңнан тайпылмыйча,
Коръән кушканча яшә!
Игелек кыл, мөселманга
Фарыз гамәл – изгелек.
Исән чакта, фанилыкта
Гыйбадәт кыл син белеп!
Изге Коръәндә бары тик
Иң пакъ яшәү үрнәге
Һәм дә кучкәч бакыйлыкка,
Күрәчәкләр гүрдәге.
Кылган гамәл тәңгәл булсын
Савапның иң зурына.
Онытмыйк барасыбызны
Аллаһы хозурына...

## Җомга көн

Җомга көнгә һич кенә дә
Мин битараф булалмыйм.
Ул көнне бит иман иңә,
Ә иманлы югалмый...
Җомга көнне без, бәндәдән,
Зур җаваплык сорала.
Чөнки Ходай каршысында
Безнең язмыш сынала.
Җомга көнне көтеп алыйк,
Кермик ят кәсепләргә.
Ислам юлын алга өндик
Һәм йөрик мәчетләргә.
Җомгадагы вәгазьләрдән
Бар борчулар югала.
Игелекләр, изге эшләр
Туа бары уйларда...
Җомга көн ул – Аллаһ биргән
Бер нигъмәтнең кисәге.
Кадерен белик, кыяматтә
Булмыйк тәмуг кисәве...
Нинди генә көн туса да,
Җанга якын җомга көн!
Иманына инанганның
Эше уңа торган көн!..

МИНЕМ ФИКЕР

# Савабы булсын дисәң...

Күптән түгел генә Тукай районы мөслимәләре үзләрен борчыган сораулар буенча район мөхтәсибе белән очрашу үткәрде. Анда авыл җирләрендә яшь имамнар юклыгы, ә кайбер авылларда инде мәчетләрнең ябылу чигендә булуы хакында борчулы фикерләр яңгырады. Гореф-гадәт буенча халык мәҗлесләрне еш үткәрә, ә бит авыл халкы мәҗлесләрдә сәдаканы, үзара алыш-биреш итмичә генә, мәчет файдасына, яшь имамнарга хезмәт хакы өчен тапшырса, бик хәерле эш булыр иде. Ләкин, ни кызганыч, халык арасында бу турыда фикер йөртүчеләр бик сирәк. Мәҗлесләрдә Коръән укучылар сәдаканы Аллаһ риза булган, Аллаһ кушкан урыннарга гына бирелергә тиешлеге турында аңлатса, халык үзгәрер иде дә бит... Коръәндә сәдакаларга кагылышлы күп аятьләр бар. Аларның кайберләрен бүген искә төшереп китсәк, бик урынлы булыр. «Бәкара» сүрәсенең 261нче аятендә Аллаһы Тәгалә: «Аллаһ юлына биргән малның мисалы – бер бөртек орлык кеби, ул орлык үстерде җиде башак, һәр башакта йөзәр орлык. Аллаһ үзе теләгән бәндәсенә җиде йөздән да арттырып бирер. Аллаһ – киңлек иясе һәм барча нәрсәне белүче». 264нче аять: «Ий мөэминнәр! Биргән сәдакаларыгызны миннәт кылып яки рәнҗетеп биреп, савабын югалтмагыз! Рия белән биргән кешеләр – кәферләр кеби, алар Аллаһыга һәм ахирәт көненә ышанмыйлар, шулай да кешеләргә яхшы күренер өчен сәдака бирәләр. Рия белән яки рәнҗетү белән бирелгән сәдаканың мисалы – өстенә туфрак кунган шома таш кеби, яңгыр суы туфракны юып төшерә дә, таш тап-такыр булып, ялангач кала. Алар биргән сәдакаларының әҗеренә ирешергә һич кадир булмаслар. Аллаһ Коръән белән гамәл кылмыйча кәфер булган кешеләрне туры юлга күндермәс». 265нче аять «Аллаһ ризалыгын өстәп, савабын өмет итеп һәм савап булачагына күңелдән нык ышанып, Аллаһ күрсәткән урыннарга сәдака бирүчеләрнең мисалы – әре яңгырлы явым яуган калку җирдәге тигез бакча кеби. Ул бакча башка бакчаларга караганда җимешне ике өлеш бирә. Әгәр ул бакчага әре яңгыр яумаса, вак яңгыр ява, һәрхәлдә, яумый калмас. Аллаһ – сезнең кылган эшләрегезне күрүче. (Аллаһ риза булырлык итеп бирелгән дөрес сәдакага, әре яңгыр яуган бакчаның уңышы кеби, савап күп булыр. Кимчелекле итеп бирелгән сәдакага да, вак яңгыр яуган бакчаның уңышы кеби, аз булса да, һаман савап булыр)». Шулай ук хәдисләрдә дә сәдакалар турында күп әйтелә. Ризаэддин Фәхреддиннең «Җәвамигуль кәлим шәрхе» («Сайланма хәдисләр җыентыгы») дип аталган хезмәте пәйгамбәребез Мөхәммәт (с.г.в.)нең төрле мәсьәләләргә багышланган 344 хәдисенә аңлатма-шәрехләрдән тора. Китапта сәдакаларга караган хәдисләр дә күп китерелә. «Байлыгы булган һәм дә әгъзалары сәламәт булып, кәсеп кылырга көчләре җиткән кешеләр өчен сәдака сорау хәләл түгел» (Сүнән Ибн Маҗәһ). «Сорау тел белән сораугa гына хас түгел. Хәл теле белән сорау да бу хәдис хөкеменә күрә хәләл түгел. Сәдака кабул итү зарурәт вә ихтыяҗ нисбәтеннән генә дөрес булып, зарурәт беткәннән соң аны кабул итү әдәп-әхлак карашында тыелган». «Сәдакалары тәртипсез булган кавемнәр байый вә мәдәният кәсеп итә алмыйлар, байлык белән мәдәният булмаган җирдә гыйлем үсми, дәвам итә алмый. Гыйлем вә мәдәният булмаса, дин яшәми. Шуның өчен булса кирәк, ислам дине сәдака хакында бик яхшы тәртипләр төзеп калдырган вә, сәдака белән гомуми милләт файдасы өчен, бик кулай ишекләр ачкан иде. Ләкин ислам дөньясы бу турыда җиңел карады, бу эшне шәригать теләгән юлдан читкә борып чыгарды. Бу хәл һаман шул, бик яхшы булмаган хәлдә дәвам итеп тора…» – ди Р.Фәхреддин. Хәдистән аңлашылганча, сәдака итеп бирелгән әйберләргә кеше мохтаҗ булырга тиеш! Акча бәрабәренә Коръән чыгу вә чыгарту турында галим: «Акча бәрабәренә дигәч тә, Коръән уку яки Коръән чыгу өчен мәгълүм суммага килешү вә нотариус яки волостька барып язышу дигән сүз түгел. Бәлки, Коръән укучыга вә чыгучы кеше үз эченнән генә шул хезмәт буш булмаслыгын белсә, шушы уку акча бәрабәренә булган укудыр. Акча алу нияте белән Коръән уку вә Коръән укыту нияте белән акча бирү Расүлуллаһ вә аның сәхабәләре заманында булганы юк вә моңа хаҗәт тә юк. Мөселманнарның һәрберсе «Фатиха» вә «Ихлас» сүрәләрен белә, бик күпләре мәгънәләрен дә аңлый. Кешегә кушып Коръән чыгаруга караганда, һәркем үзе ихлас белән «Фатиха» вә «Ихлас» сүрәсен укып, Аллаһы Тәгаләгә түбәнчелек вә бәндәчелек күрсәтүе яхшырактыр», – дип аңлата. Сәдакалары тәртипсез булган кавемнәр байый вә мәдәният кәсеп итә алмыйлар… Гыйлем вә мәдәният булмаса, дин яшәми… Бүгенге көндә моңа ачык дәлилләр күп, бигрәк тә хезмәт хакы булмаганлыктан авылларда гыйлемле яшь имамнар сирәк. Мәҗлесләрдә катнашучы милләттәшләрем, бер-берегез белән акча алыштыруны туктатырга вакыт җиткәндер инде! Мәчет-мәдрәсәләрне карау, имамнарны хезмәт хакы белән тәэмин итү элек-электән халык өстендә булган, шуны онытмыйк! «Адәм баласы вафат булганнан соң, бөтен гамәле киселә, мәгәр дә ошбу гамәлләр генә артыннан барып торыр: халык файда алырлык рәвештә нәшер кылып калдырган гыйлеме, изге баласы, мирас итеп калдырган Коръән-Кәрим нөсхәсе, бина кылган мәчете, мосафирлар файдалансын өчен салдырган йорты, агызып калдырган елгасы, үзе сәламәт вакытында хәер өчен аерган сәдакасы. Шул нәрсәләрнең савабы үзе артыннан барып торыр» (Сүнән Ибн Маҗәһ).

**Язманы Теләнче Тамак мәчете мөгаллимәсе Сөмбелә Фәхертдинова әзерләде.**

## Колак салсаң, үкенмәссең

* Җир йөзендә Аллаһка иң сөекле урыннар – мәчетләр

* Кешеләр мәчетләр белән мактаныша башлаганчы Кыямәт купмас

* Мәчетләр Аллаһны зикер итәр өчен һәм намаз укыр өчен генә төзелде

* Мөселман кешесе мәчеткә кергәндә үк Пәйгамбәребез (с. г. в.) өйрәткән догаларны укып керергә тиеш: "Әй Аллаһ, миңа рәхмәт ишекләреңне ач".

* Мәчеттән чыкканда да дога укып чыгарга тиеш: "Әй Аллаһ, миңа фазыйлә ишекләреңне ач".

* Киемнәрегездән агын киегез, чөнки ул – киемнәрегезнең иң хәерлесе

* Әгәр Аллаһы Тәгалә бер кавемгә чир җибәрергә теләсә, мәчет әһелләренә карап һәм ул бәлане кире кайтарыр

* Әгәр бер кешенең мәчеткә даими йөрүен күрсәгез, аның иманлы булуына шаһитлек бирегез

* Сарыкларның бүресе булган кебек үк, шайтан – кешенең бүресе, бүре аерылган һәм читтә йөргән сарыкларны ала. Берүк аерылудан сак булыгыз, җәмәгать белән, күпчелек белән һәм мәчетләр белән бергә булыгыз!

# ДОГА



Дога – кешенең Аллаһка ялваруы, мөрәҗәгате, теләкләре. Мөселманнар гадәттә дога итеп Коръән аятьләрен һәм хәдисләрдә китерелгән дога үрнәкләрен куллана. Алар оригиналда, ягъни гарәпчә укыла.

Коръәндә дога рәвешендә килгән 200ләп аять билгеле. Намазда иң күп укылган "Фатиха" сүрәсендә дә дога-ялвару сүзләре бар. Ягъни намаз укыган кеше көненә күп тапкырлар дога да кыла.

Һәр намаз ахырында укылучы гүзәл догаларның берсе — РАББӘНӘ догасы, ягъни Коръәндәге "Бәкара" сүрәсенең 201нче аяте:

«Раббәнәә әәтинә фид-дүнйәә хәсәнәтән үә фил-әәхырати хәсәнәтән үә кыйнәә гәҙәәбән-нәәр» («Әй Раббыбыз! Безгә дөньяда һәм ахирәттә яхшылык бир, безне җәһәннәм газабыннан сакла»).

Моннан тыш без үз сүзләребез, туган телебез белән яки уй-йөрәгебез, ихлас күңелебез белән Аллаһка үтенечләребезне юллыйбыз — бу да дога була.

Дога — йөрәкнең Аллаһ белән сөйләшүе ул. Галимнәр әйтүенчә, дога — мөселманның коралы, диннең терәге, галәмнәрнең нуры. Аның кабул булуына ихлас ышанырга кирәк. Дога кабул булуның кайбер билгеләре — күздән яшь чыгу, тирләү.

**Дилбәр Булатова, Уфа шәһәре.**

## Бергә булыйк

*Хөрмәтле укучыларыбыз! "Ислам нуры" - шактый еллар дәвамында күпләрегез яратырга өлгергән бай эчтәлекле газета. Кулдан язылган хатларыгызны алып уку, андагы теләк-тәкъдимнәрегезне, җылы сүзләрегезне ишетү безнең өчен дә бик күңелле. Ике арадагы шушы элемтәләр өзелмәсен, алдагы көннәрдә дә бергә булыйк! Газета битләрендә белдерүләр, реклама текстлары да урнаштырырга мөмкин.*



*"Ислам нуры"на почта бүлекләрендә, Татарстан буенча гына түгел, Россиянең бөтен төбәкләрендә язылырга мөмкин. Индексы - 54149.*

*Бәйге! Бәйге! Бәйге!*

**"МИНЕМ ЮЛЫМ"**

## Җиңүче билгеле!

Кадерле дуслар! Газетада "Минем юлым" дигән бәйге игълан иткән идек. Әле ел тәгәлләнмәсә дә, уйлаштык-уйлаштык та, беренче яртыеллыкның җиңүчесен билгеләргә булдык. Ул – даими авторыбыз, Зәй районы Аксар авылыннан Салих хәзрәт Зиннәтов. Алла боерса, шушы көннәрдә аңа истәлекле бүләкләрне юлларбыз.

# ӘРЕКМӘН



Күп кенә бакчачылар әрекмәнне бернигә кирәкмәгән чүп үләненә санап, бик нык ялгыша. Халык дәвасында әрекмән яфраклары, орлыклары һәм тамырларының бик тә шифалы булуы мәгълүм.

Әрекмәннең файдасын, шифалы үзлекләрен санап бетергесез. Аннан су белән ясалган төрле төнәтмәләр микробларны үтерергә сәләтле, ялкынсынуга, ярсынуга, шешләргә каршы һәм тирләткеч чара буларак уңышлы кулланыла. Өстәвенә, алар матдәләр алмашын көчәйтә, бавыр эшчәнлеген яхшырта, еш кына бәвел-җенес органнарына бәйле авыруларны дәваларга булышалар (хатын-кызларда да, ирләрдә дә), кандагы артык холестеринның, тәндәге артык сыеклыкның чыгуына тәэсир итәләр, бит һәм аяк-куллар шешүне булдырмый калырга мөмкинлек бирәләр.

Табибләр әрекмәннең төрле өлешләреннән әзерләнгән даруларны бөер һәм бәвел ташы авыруы, умыртка авырулары (бил сызлау кебек), буыннар сызлаганда, тоз утыруы, шикәр чиренең башлангыч төре, яман булмаган һәм хәтта яман шешләрне дәвалаганда эчәргә киңәш итәләр.

Шуның белән берррәттән, әлеге үсемлек нигезендә йорт шартларында әзерләнгән яки даруханәләрдә сатыла торган даруларны салкын тигәндә, тамак бакасы вакытында, үпкә ялкынсынуның һәм туберкулезның башлангыч төрендә, ашказаны-эчәк юллары авырулары, дәвамлы эч катулар, бизгәк вакытында, бәвел чыгуга бәйле борчулар күзәтелгәндә, тир кую чарасы буларак кулланырга киңәш ителә.

Бәйләвечләр, чылаткычлар, шулай ук әрекмән яфраклары һәм тамырлары суы сөт бизләре шеше, кычыткы, бетчәләр, тимрәү, авыр төзәлүче җәрәхәтләр, төрле киселүләрне дәвалаганда бик тә файдалы. Үлекле бетчәләр, коры сөялләр булганда, тән тиресе кычытканда, барлык дәрәҗәдәге пешүләр, кавык күзәтелгәндә, чәчләр коелганда һ.б. очракларда да файдасы тими калмас.

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррир**
**Айгөл Абдуллина**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

"Роспечать" агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы 1280.**

**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**25 июнь 16 сәг.**
**фактта 25 июнь 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**